СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ | КАРАР

«30» июль, 2024 ел | Алабуга шәһәре | № 368

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы депутаты статусы турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның 12 октябрендәге 203 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Гамәлдәге законнарга туры китерү сәбәпле, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы

КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы депутаты статусы турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның 12 октябрендәге 203 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядәге 1.4. пунктчасы белән тулыландырырга:

«14) аның чит ил агенты статусын алуы.».

1.2. 3 статьяны түбәндәге редакциядәге 1.1. өлеше белән тулыландырырга:

«1.1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы депутатының вәкаләтләре депутат җитди сәбәпләрсез алты ай рәттән район Советының барлык утырышларында катнашмаган очракта, район Советы карары белән вакытыннан алда туктатыла.».

1.3. 3 статьяның 3 өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыклары (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга.

1.4. 18 статьяның 1 өлешендәге 2 пунктның «б» пунктчасында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыклары (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль төзелеш һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Комиссия рәисе урынбасары Р.Л. Исланов